КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 17 ноябрь г.Казань № 1005

Гражданнарга су белән тәэмин итү хезмәтләре өлешендә коммуналь хезмәтләргә түләүгә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Гражданнарга су белән тәэмин итү хезмәтләре өлешендә коммуналь хезмәтләргә түләүгә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Гражданнарга су белән тәэмин итү хезмәтләре өлешендә коммуналь хезмәтләргә түләүгә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 17 ноябрь, 1005 нче
карары белән расланды

Гражданнарга су белән тәэмин итү хезмәтләре өлешендә
коммуналь хезмәтләргә түләүгә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен
Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына
Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип гражданнарга су белән тәэмин итү хезмәтләре өлешендә коммуналь хезмәтләргә түләүгә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар гражданнарга су белән тәэмин итү хезмәтләре өлешендә коммуналь хезмәтләргә түләү өчен өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына (алга таба – башка бюджетара трансфертлар алучылар) бирелә.

3. Башка бюджетара трансфертлар түбәндәге шартларны үтәгәндә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә:

муниципаль район территориясендә су белән тәэмин итү хезмәтләре күрсәтүче коммуналь оешма өчен Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты тарафыннан халык өчен су белән тәэмин итү хезмәтләренә тарифларның дифференциацияләнгән күләмнәре билгеләнде; шул ук вакытта муниципаль районның шәһәр халкы һәм авыл халкы өчен тарифларда аерма 1,8 тапкырдан артыграк тәшкил итә;

Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы мәгълүматлары буенч, агымдагы ел башына муниципаль берәмлек халкы саны – 34 000 нән 35 000 гә кадәр, шул исәптән шәһәр халкы 13 000 нән 14 000 гә кадәр тәшкил итә;

су белән тәэмин итү хезмәтләре өлешендә коммуналь хезмәтләргә түләү өчен максатчан субсидия бирү турында муниципаль хокукый акт булу.

4. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләре белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү тиешле елга һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

6. Башка бюджетара трансфертлар алучыларга башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

7. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен башка бюджетара трансфертлар алучылар Министрлыкка, шәхсиләштерелгән исәпкә алу системасында факттагы исәпләүләр нигезендә формалаштырылган бирелергә тиешле субсидияләр күләмен хисаплауны теркәп, ирекле рәвештә язылган башка бюджетара трансфертлар бирү турында гариза (алга таба – гариза) кертә.

8. Башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы карар Министрлык тарафыннан гариза кергән көннән бер эш көне эчендә кабул ителә.

Гариза бу Тәртипнең 7 нче пунктына туры килмәгән очракта, шулай ук башка бюджетара трансфертлар алучы тарафыннан бу Тәртипнең 3 нче пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларны бирү шартлары үтәлмәгән очракта, Министрлык гаризаны кабул итми һәм гариза кергән көннән эш көннәрендә исәпләнүче биш көн эчендә, гаризаны кабул итмәүнең сәбәпләрен күрсәтеп, бу турыда башка бюджетара трансфертлар алучыга хәбәр итә.

9. Башка бюджетара трансфертлар алучы, бу Тәртип белән билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, гаризаны кабул итмәү турында хәбәрнамә алган көннән эш көннәрендә исәпләнүче 10 көн эчендә кабат гариза бирергә хокуклы.

10. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык һәм башка бюджетара трансфертлар алучы арасында башка бюджетара трансфертлар бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче җиде көн эчендә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә бирелә, анда түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертлар бирү максаты, шартлары һәм тәртибе;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе, күләме һәм вакытлары;

башка бюджетара трансфертлар алучы тарафыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

бу Тәртип белән билгеләнгән шартлар бозылган очракта, килешүне өзү тәртибе;

башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап бирү формасы, вакытлары һәм тәртибе;

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары тарафыннан башка бюджетара трансфертлар алучының Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру хокукы.

11. Министрлык башка бюджетара трансфертларны башка бюджетара трансфертлар алучыларның Федераль казначылыкның территориаль органнарында ачылган шәхси счетларына күчерә.

12. Башка бюджетара трансфертларны алучы башка бюджетара трансфертлардан файдалану турындагы хисапны Министрлыкка килешү белән күздә тотылган форма һәм тәртип нигезендә кертә.

13. Башка бюджетара трансфертлар алучы хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмавы өчен законнар нигезендә җавап бирә.

14. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмауны тикшерүдә тотуны Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанслар министрлыгы законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

15. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләттерелә.

16. Агымдагы елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләттерелергә тиеш.